# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛАННЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXXXIII УТЫРЫШЫ

## К А Р А Р № 71

Баланны авылы

«21» июнь 2024 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланны авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланны авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2021 елның “19” нче ноябрендәге 26 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Федераль законнарына туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланны авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланны авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланны авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы 2021 елның “19” нче ноябрендәге 26 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 1.7 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) планлаштыру структурасы элементлары (зоналар (массивлар), районнар (шул исәптән торак районнар, микрорайоннар, кварталлар, сәнәгать районнары), яр буйлары, гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм коммерциягә карамаган берләшмәләрен урнаштыру территорияләре;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татартсан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Баланны авылы җирлеге башлыгы: Гильфанова И.Х.